ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлеге Баланлы авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17 ноябрь 2023 ел №1

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 нче елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез,2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең Баланлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум, моннан тыш, түбәндәге категория гражданнар: 1 һәм 2 группа инвалидлары, Әфганстандагы сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге уку формасындагы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме һәм ЛНР һәм ДНР да махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук хатынына (иренә), балигъ булган балаларына, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын» үзара салымын түләүдән азат итүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту:

- Баланлы авылының Яшьләр урамы, Совет урамы юлларын кышкы тоту;

- Баланлы авылының Яшьләр урамы, Совет урамы юлларын җәйге тоту;

- Баланлы авылы Яшьләр, Совет урамнарын сибеп грейдировкалау килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү;

Совет урамында вак таш салу;

Баланлы авылының Совет, Яшьләр урамнарында чокырлы ремонт үткәрү;

- су басу вакытында торбаларны кардан чистарту;

- юл буендагы үләннәрне чабу;

. 2) ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:

Баланлы авылы зиратының коймасын ремонтлау;

Баланлы авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу;

Баланлы авылы зиратлары территориясендә үлән чабу;

Баланлы авылы зираты территориясендә карт агачларны кисү;

Баланлы авылы зиратының коймасын буяу.

3) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау:

- су башнясын ремонтлау;

су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;

- су сыйфатын анализлау;

су башнясының санитар саклау зонасында үләнне чабу;

4) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

Совет урамындагы балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу;

- "Сабантуй"паркын ремонтлау өчен материаллар сатып алу

халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу;

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- Баланлы авылында янгын гидрантларын ремонтлау;

- янгын күрсәткечләрен сатып алу.

6) урам яктырту җайланмасы:

- урам яктыртуга хезмәт күрсәтү, яктырткычлар сатып алу;

7) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү:

- "Мәкәр" чишмәсен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 195 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 107, бу 55% тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
Гражданнар җыенында катнашкан 78 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 29 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

-Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Баланлы авыл җирлегенең Баланлы авылында узган гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

- 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең Баланлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум, моннан тыш, түбәндәге категория гражданнар: 1 һәм 2 группа инвалидлары, Әфганстандагы сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге уку формасындагы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
- ЛНР һәм ДНР да махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук хатынына (иренә), балигъ булган балаларына, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарына» үзара салымын түләүдән азат итәргә.
- Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту:

- Баланлы авылының Яшьләр урамы, Совет урамы юлларын кышкы тоту;

- Баланлы авылының Яшьләр урамы, Совет урамы юлларын җәйге тоту;

- Баланлы авылы Яшьләр, Совет урамнарын сибеп грейдировкалау килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү;

Совет урамында вак таш салу;

Баланлы авылының Совет, Яшьләр урамнарында чокырлы ремонт үткәрү;

- су басу вакытында торбаларны кардан чистарту;

- юл буендагы үләннәрне чабу;

. 2) ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:

Баланлы авылы зиратының коймасын ремонтлау;

Баланлы авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны ташу;

Баланлы авылы зиратлары территориясендә үлән чабу;

Баланлы авылы зираты территориясендә карт агачларны кисү;

Баланлы авылы зиратының коймасын буяу.

3) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау:

- су башнясын ремонтлау;

су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү;

- су сыйфатын анализлау;

су башнясының санитар саклау зонасында үләнне чабу;

4) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

Совет урамындагы балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу;

- "Сабантуй"паркын ремонтлау өчен материаллар сатып алу

халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу;

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- Баланлы авылында янгын гидрантларын ремонтлау;

- янгын күрсәткечләрен сатып алу.

6) урам яктырту җайланмасы:

- урам яктыртуга хезмәт күрсәтү, яктырткычлар сатып алу;

7) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү:

- "Мәкәр" чишмәсен төзекләндерү.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Баланлы авыл
җирлеге башлыгы И.Х.Гыйлфанова